**Совет Большекургузинского сельского поселения**
**Зеленодольского муниципального района**
**Республики Татарстан**

# РЕШЕНИЕ
# КАРАР

24 июнь 2015 ел № 201

Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының 2014 елның
17 ноябрендә кабул ителгән 164 номерлы «физик
затлар милкенә салым турында»гы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Олы Карауҗа авыл җирлеге Советы **карар бирде:**

1. Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының 2014 елның 17 ноябрендәге «Физик затлар милкенә салым турында» гы 201 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә: 1) 2 пунктта:

1.1) 1 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектында урнашкан салым түләүченең теләге буенча бер гараж яисә машина урынына карата»;

1.2) 4 пунктчада::

1.2.1) беренче абзацта "2 процент" сүзләрен «2015 елда -1,5 процент, 2016 елда -1,8 процент, 2017 елдан – 2 процент " сүзләренә алмаштырырга»»

1.2.2) дүртенче абзацны төшереп калдырырга;

1.3) 4 пункттан соң түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктчага өстәргә:

« 4.1) Салым салу объектларына карата 2 процент, кадастр бәясе аларның һәркайсының бәясе 300 миллион сумнан артып китә;»;

2) 2 пункттан соң түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункт өстәргә:

«2.1. Ташлама ике фатирдан торган күп фатирлы торак йорттагы фатир милекчеләренә әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метрына салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган салым суммасын киметү рәвешендә бирелә. Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында аның өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Бу очракта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 1 гыйнвардан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла..

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында кабул ителгән көннән биш көнгә дә соңга калмыйча (http://zelenodolsk.tatarstan.ru)

**Олы Карауҗа**
**Авыл Җирлеге Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **М.Г. Шакиров**